ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында” 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның беренче өлешендә:
а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:”;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасы – дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре өлкәсендә өстенлекләргә һәм максатларга ирешүне тәэмин итә торган дәүләт сәясәте чаралары (бурычлары, башкару сроклары һәм ресурслары буенча үзара бәйле) һәм инструментлары системасы.”;
в) икенче өлештә “Әлеге Законда” сүзләрен “2. Әлеге Законда” сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасын гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары башкара.”;
б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:
“4. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру, үстерү һәм алардан файдалану вәкаләтләрен бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы һәм аның тарафыннан билгеләнә торган дәүләт учреждениесе йә дәүләт унитар предприятиесе гамәлгә ашыра.";

3) 6 статьяда:

а) 1 өлештә "өч елга" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 өлештә "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында" 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләрен "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 статьяда:

а) 2 өлештә "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында" 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләрен "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлештә "Электрон санлы имза белән" сүзләрен "Электрон имза белән" сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяның 1 өлешендә "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында" 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләрен "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда" сүзләренә алмаштырырга;

6) $11^1$ статьяның 2 өлешендә "вәкаләтле бюджет учреждениесе" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 11 апреле
№ 25-ТРЗ